СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**карары**

**«24» апрель 2023 ел** **№ 94**

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2022 елның 24 октябрендәге 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының «Шушмабаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 24 октябрендәге 77 номерлы карары белән расланган Шушмабаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1. «3. Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне срогыннан алда туктату өчен нигез туган көн булып әлеге гаризаның Шушмабаш авыл җирлеге Советына кергән көн тора.»;

1.2. 18 статьяның 1 пунктының б пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәр итеп;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690009210 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ"
ИНН1609012678